**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 126-15 «25» февраль 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2019 елның 23 маендагы 264-36 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш итү тәртибе турында нигезләмә хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш итү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Граждан кодексының беренче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 21 декабрендәге 430-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Азнакай шәһәр прокуратурасының 2022 елның 28 гыйнварындагы 02-08-02/2022 номерлы протестын исәпкә алып,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2019 елның 23 маендагы 264-36 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш итү тәртибе турында нигезләмә хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш итү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 15.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.2. Хуҗасыз күчемсез әйбер исәпкә куелган көннән соң бер ел узгач, ә сызыкча объектны исәпкә куйган очракта, исәпкә куелган көннән соң өч ай узгач, Палата бу әйбергә муниципаль милек хокукын тану турында дәгъва гаризасы белән судка мөрәҗәгать итә.».

- түбәндәге эчтәлекле 15.2.1 пункт өстәргә:

«15.2.1. 15 нче бүлекнең 15.1 пунктында күрсәтелгән орган белән бергә

хуҗасыз линия объектларын исәпкә алу турында гариза белән шундый линия объектларны закон нигезендә эксплуатацияләүне башкарырга тиешле затлар мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Закон нигезендә мондый линияле объектларны эксплуатацияләүне башкарырга тиешле затлар исәпкә алынмаган линия объектларын куйган көннән соң өч ай узгач, аларга милек хокукын тану таләбе белән судка мөрәҗәгать итәргә мөмкин.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга:http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин